ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 144-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары Ю.З. Камалтынов, А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 144-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе — Ф.Х. Мөхәммәтшин

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ АППАРАТЫ
АППАРАТ ГОСУДАРСТВЕННОГО СОВЕТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
БЕРКЕТМӘ БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ ОТДЕЛ

Казан шәһәре
2025 елның 24 декабре
№ 517-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
Ю.З. Камалтынов,
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында»**
**Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасының дәүләт символлары турында» 1999 елның 14 июлендәге 2284 номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 1999, № 8 (I өлеш); 2003, № 8; 2006, № 2 (I өлеш), № 11 (I өлеш); 2013, № 3; 2016, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2022, № 83 (I өлеш), 2023, № 27 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) преамбуланың беренче абзацында «Татарстан халкының» сүзләрен «Татарстанның күпмилләтле халкының» сүзләренә алмаштырырга;

2) 2 статьяда:
а) беренче өлештә:
1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«1) Татарстан Республикасы Рәисе резиденциясе бинасы фасадында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты бинаалары фасадында, Татарстан Республикасы дәүләт органнары, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы бинаалары фасадларында яисә шушы бинааларның элмә такталарында;»;
2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
«2) Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең, Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренең, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, вазыйфасына Татарстан Республикасы Рәисе тарафыннан

билгеләнеп куела торган Татарстан Республикасы вәкилләренең, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларының эш кабинетларында;

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты утырышлары, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Президиумы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Президиумы утырышлары, Татарстан Республикасы Конституция советы, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары утырышлары үткәрелә торган залларда, Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд утырышлары залларында, граждан хәле актларын дәүләт теркәвенә алуны гамәлгә ашыручы органнарның тантаналы церемонияләр залларында;»;

3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) Татарстан Республикасы законнары бланкларында, Татарстан Республикасы Рәисе, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы һәм аның органнары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы Рәисе Администрациясе һәм аның структур бүлекчәләре, Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары, Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил документларының мөһерләрендә һәм бланкларында, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Ярлыкау мәсьәләләре комиссиясе, Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы документларының бланкларында;»;

б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының Дәүләт гербы сурәте түбәндәгеләрдә урнаштырылырга мөмкин:

Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрендә һәм аларга документларда;

Татарстан Республикасы дәүләт органнары тарафыннан гамәлгә куелган һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре булып тормаган күкрәк билгеләрендә һәм медальләрдә;

гамәлгә куючысы Татарстан Республикасы булган оешмалар бланкларында һәм мөһерләрендә.»;

г) түбәндәге эчтәлекле өлеш өстәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт гербын, шул исәптән аның сурәтен, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар тарафыннан куллану, әгәр ул Татарстан Республикасы Дәүләт гербына ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтү булмаса йә аңа карата ачыктан-ачык илтифатсыз булуны күрсәтмәсә, башка очракларда рөхсәт ителә.»;

3) 4 статьяның икенче өлешендә «йә предприятие, учреждение» сүзләрен төшереп калдырырга;

4) 5 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**5 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт гербын әлеге Законны бозып йә аңа карата ачыктан-ачык илтифатсыз булуны күрсәтә торган ысуллар белән куллану, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт гербына ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтү Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.»;

5) 7 статьяда «төшерелгән бланкларны» сүзләрен «сурәтләнгән бланкларны һәм мөһерләрне» сүзләренә алмаштырырга;

6) 9 статьяда:

а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**9 статья.** Татарстан Республикасының Дәүләт флагы түбәндәге урыннарда күтәрелә (урнаштырыла):

1) Татарстан Республикасы Дәүләт Советы утырышлары үткәрелә торган биналарда – утырышны үткәрүнең барлык чорына;

2) Татарстан Республикасы Рәисе резиденциясе бинасында, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы дәүләт органнары биналарында, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесе, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасы җәмәгать судьялары, җирле үзидарә органнары урнаша торган биналарда, әлеге өлешнең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, – даими рәвештә;

3) Татарстан Республикасы дәүләт органнары гамәлгә куючы функцияләрен үзләренә карата гамәлгә ашыра торган оешмалар биналарында, шулай ук күпфатирлы йортлар биналарында – федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә билгеләнгән бәйрәм көннәрендә һәм истәлекле көннәрдә;

4) Татарстан Республикасы дәүләт органнары булган, Россия Федерациясе территориясеннән читтә урнашкан Татарстан Республикасы вәкиллекләре биналарында – халыкара хокук нормалары, дипломатик беркетмә кагыйдәләре һәм шушы ил традицияләре нигезендә.»;

б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт флагы шулай ук дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм милек рәвешләренә бәйсез рәвештәге оешмалар үткәрә торган церемонияләр һәм башка тантаналы чаралар булганда, шулай ук гаиләләрнең тантаналы чаралары вакытында күтәрелергә (урнаштырылырга) мөмкин.»;

г) дүртенче өлештә «гомуми белем бирү оешмалары» сүзләрен «мәгариф оешмалары» сүзләренә алмаштырырга;

7) 10 статьяда:

а) беренче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**10 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт флагы Татарстан Республикасы Дәүләт Советы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең вәкиллекле органнары утырышлары залларында, Татарстан Республикасы җәмәгать судьяларының суд утырышлары залларында, Татарстан Республикасы Рәисенең, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Рәисенең, Татарстан Республикасы Премьер-министрының, Татарстан Республикасы Дәүләт Киңәшчесенең, Татарстан Республикасы дәүләт органнары җитәкчеләренең, Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Эшкуарлар хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкилнең, Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре башлыкларының эш кабинетларында;»;

б) икенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

в) өченче өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт флагы Татарстан Республикасы Рәисе катнашында тантаналар чаралар (церемонияләр) үткәрү өчен билгеләнгән урыннарда урнаштырыла.»;

г) дүртенче өлешне үз көчен югалткан дип танырга;

8) 12 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

9) 13 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**13 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт флагын әлеге Законны бозып йә аңа карата ачыктан-ачык илтифатсыз булуны күрсәтә торган ысуллар белән куллану, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт флагына ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтү Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.»;

10) 14 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**14 статья.** Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар үткәрә торган церемонияләр һәм башка тантаналы чаралар булганда, Татарстан Республикасының Дәүләт флагын күтәрү (урнаштыру) шушы органнар һәм оешмалар җитәкчеләренең күрсәтмәсе белән башкарыла.»;

11) 15 статьяда:

а) икенче өлештә «йә предприятие, учреждение» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) өченче өлештә «йә предприятие, учреждение» сүзләрен төшереп калдырырга;

12) 16 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**16 статья.** Матәм көннәрендә Татарстан Республикасы Дәүләт флагы токтасының өске өлешенә озынлыгы флаг тукымасы озынлыгына тигез булган кара тасма беркетелә. Мачтада (флагштокта) күтәрелгән Татарстан Республикасы Дәүләт флагы мачта (флагшток) биеклегенең яртысына кадәр төшерелә.»;

13) 17 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**17 статья.** Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең, иҗтимагый берләшмәләрнең, милек рәвешләренә бәйсез рәвештәге оешмаларның флаглары Татарстан Республикасының Дәүләт флагын кабатларга тиеш түгел, ул шушы флагларның нигезе сыйфатында да кулланылырга тиеш түгел.»;

14) II бүлеккә түбәндәге эчтәлекле 17[1] статья өстәргә:

«**17[1] статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт флагын, шул исәптән аның сурәтен, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар тарафыннан куллану, әгәр ул Татарстан Республикасы Дәүләт флагына ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтү булмаса йә аңа карата ачыктан-ачык илтифатсыз булуны күрсәтмәсә, башка очракларда рөхсәт ителә.»;

15) 19 статьяда:

а) дүртенче абзацта «сессияләрен» сүзен «утырышларын» сүзенә алмаштырырга;

б) җиденче абзацта «Татарстан Республикасы тормышындагы» сүзләрен «Татарстан Республикасында» сүзләренә алмаштырырга;

в) тугызынчы абзацны төшереп калдырырга;

16) 20 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

17) 21 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**21 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт гимны «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең телетапшыруларын һәм радиотапшыруларын трансляцияләгәндә башкарылырга мөмкин.

Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын башкару, әгәр ул Татарстан Республикасы Дәүләт гимнына ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтү булмаса йә аңа карата ачыктан-ачык илтифатсыз булуны күрсәтмәсә, башка очракларда әлеге Законда билгеләнгән таләпләрне үтәп рөхсәт ителә.»;

18) 22 статьяда «Татарстан Республикасының Эчке эшләр министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

19) 23 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**23 статья.** Татарстан Республикасы Россия Федерациясе территориясеннән читтә чаралар үткәргәндә Татарстан Республикасы Дәүләт гимны халыкара хокук нормаларына, дипломатик беркетмә кагыйдәләренә һәм шушы ил традицияләренә туры китереп башкарыла.

Татарстан Республикасы Россия Федерациясенең башка субъектлары территорияләрендә чаралар үткәргәндә Татарстан Республикасы Дәүләт гимны федераль законнар, әлеге Закон һәм Россия Федерациясенең тиешле субъекты законнары нигезендә башкарыла.»;

20) 24 статьяның беренче өлешендә «вокаль яисә инструменталь вариантта» сүзләрен «вокаль һәм (яисә) инструменталь вариантта» сүзләренә алмаштырырга, икенче җөмләне түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Шул ук вакытта тавыш яздыру һәм видеога яздыру чаралары, шулай ук телевидение һәм радио аша трансляцияләү чаралары кулланылырга мөмкин.»;

21) 26 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«**26 статья.** Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын әлеге Законны бозып йә аңа карата ачыктан-ачык илтифатсыз булуны күрсәтә торган ысуллар белән куллану, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт гимнына ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтү Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка китерә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

**«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) «Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законы нигезләмәләрен федераль законнар һәм республика законнары нормаларына туры китереп актуальләштерү максатларында эшләнде.

Закон проектында Татарстан Республикасы Дәүләт гербын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт флагын, шул исәптән аларның сурәтләрен, дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр һәм оешмалар тарафыннан башка очракларда (әлеге Законда каралмаган очракларда) куллану нормасы беркетелә, әгәр мондый куллану Татарстан Республикасы Дәүләт гербына, Татарстан Республикасы Дәүләт флагына ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтү булмаса һәм аңа карата ачыктан-ачык илтифатсыз булуны күрсәтмәсә. Шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын башка очракларда (әлеге Законда каралмаган очракларда) башкару мөмкинлеге карала, әгәр мондый башкару Татарстан Республикасы Дәүләт гимнына ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәтү булмаса һәм аңа карата ачыктан-ачык илтифатсыз булуны күрсәтмәсә.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы Дәүләт гербы сурәтен Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләренә һәм аларның документларына; Татарстан Республикасы дәүләт органнары тарафыннан гамәлгә куелган һәм Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләре булып тормаган күкрәк билгеләренә һәм медальләренә; Татарстан Республикасы тарафыннан гамәлгә куелган оешмаларның бланкларында һәм мөһерләрендә урнаштыру мөмкинлеге каралган норма кертелә.

Закон проектында биналарында (территорияләрендә) даими рәвештә Татарстан Республикасы Дәүләт флагы күтәрелгән (урнаштырылган) белем бирү оешмалары даирәсе киңәйтелә. Шулай итеп, Татарстан Республикасы Дәүләт флагы милек рәвешләренә бәйсез рәвештә барлык белем бирү оешмалары биналарында даими рәвештә куела йә аларның территорияләрендә даими рәвештә урнаштырыла.

Закон проектында Россия Федерациясе территориясеннән читтә, шулай ук Россия Федерациясенең башка субъектлары территорияләрендә чаралар үткәргәндә Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын башкару өлешенә караган нигезләмәләр төгәлләштерелә.

Закон проектында Татарстан Республикасы Дәүләт гербын, Татарстан Республикасы Дәүләт флагын һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын әлеге Законны бозып йә аңа карата ачыктан-ачык илтифатсыз булуны күрсәтә торган ысуллар белән кулланган өчен, шулай ук Татарстан Республикасы Дәүләт гербына, Татарстан Республикасы Дәүләт флагына һәм Татарстан Республикасы Дәүләт гимнына ачыктан-ачык ихтирамсызлык күрсәткән өчен Татарстан Республикасы законнары нигезендә җаваплылыкка тартуга китерә торган нигезләмәне кертү карала.

Моннан тыш, закон проекты белән «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең телетапшыруларын һәм радиотапшыруларын трансляцияләгәндә Татарстан Республикасы Дәүләт гимнын башкару турында нигезләмәләр төгәлләштерелә. Татарстан Республикасы Дәүләт гимны «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе» акционер җәмгыятенең телетапшыруларын һәм радиотапшыруларын трансляцияләгәндә көн саен башкарылу мөмкинлеге билгеләнә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары актлары ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә Татарстан Республикасы законнары актларының үз көчен югалтуын тану, аларны туктатып тору, үзгәртү яисә яңаларын кабул итү таләп ителми.

**«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

## ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ

«Татарстан Республикасы дәүләт символлары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.